ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 529-208/кс-2020

Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2021 ел өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Татэнерго» АҖ) тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» АҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны

чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 529-208/кс-2020
/карарына кушымта

## Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» АҖ тарафынан бирелә торган кайнар суга 2021 ел өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Җылылык саклау компоненты, сум/куб.м. | Җылылык энергиясе компоненты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Бер ставкалы, сум/Гкал | Ике ставкалы | |
| | | | | | Егәрлек өчен ставка, аена мең сум/1 Гкал/сәг. | Җылылык энергиясе ставкасы, сум/Гкал |
| 1 | «Татэнерго» АҖ* | | | | | |
| 1.1 | Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре | | | | | |
| 1.1 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 22,77 | 1588,19 | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 22,77 | 1658,07 | - | - |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)** | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 27,32 | 1905,83 | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 27,32 | 1989,68 | - | - |
| 1.2. | Яр Чаллы шәһәре | | | | | |
| 1.2.1 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 31,99 | 1403,98 | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 32,85 | 1465,76 | - | - |
| 1.2.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 38,39 | 1684,78 | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 39,42 | 1758,91 | - | - |

<*> «Татэнерго» АҖ өчен җылылык саклау матдәсенә җылылык саклау матдәсенә булган компонентларны исәпкә алып кулланыла торган тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ««Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.12.2018 № 5-89/тэ карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 5-31/тэ, 04.12.2020 № 343-53/тэ-2020 карарлары редакциясендә) нигезендә билгеләнгән.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге